**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 12 апрель

№ 214

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2018 елларга республика башкарма хакимият органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2016 ел, 02 март, 129 нчы карары белән расланган 2016 – 2018 елларга республика башкарма хакимият органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2018 елларга республика башкарма хакимият органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен раслау турында» 2016 ел, 02 март, 129 нчы карары белән расланган 2016 – 2018 елларга республика башкарма хакимият органнарына халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча идарә итүгә дәүләт йөкләмәсенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» бүлегенең 1 һәм 2 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1 | Яшәү дәрәҗәсе (типлаштырылган гаиләнең бер гаилә әгъзасына минималь куллану бюджетына карата халыкның җан башына акчалата керемнәре), тапкыр | квартал саен | 2,54 | 2,36 | 1,87 | 2,18 | 2,40 | 2,60 | 2,45 | 2,52 |
| 2 | Халыкның гомуми санында керемнәре минималь куллану бюджеты хакы зурлыгынннан югарырак булган халык өлеше, процент | еллык | 78,6 | 72,5 | х | х | х | 71,8 | 73,2 | 77,6»; |

«Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы» бүлегенең 1 пунктындагы 3 графада «еллык» сүзен «квартал саен» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе» бүлегенең 2 пунктындагы 3 графада «еллык» сүзен «квартал саен» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков